ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 65 от «18» 02 2021 г.

Мамадыш муниципаль районы Башкарма
комитеты каршындагы Иҗтимагый торак
комиссиясе турында нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» федераль программасын, «Социаль ипотека» республика программасын гамәлгә ашыру һәм торак шартларын яхшыртуга ярдәм итү, җәмәгать контролен һәм коррупцион хокук бозуларны профилактикалау, авыл җирлегендә торак төзү һәм сатып алу өчен социаль түләүләр алучыларның җыелма исемлекләренә кертелгәндә, гражданнарга торак шартларын яхшыртуга ярдәм итү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 6 апрелендәге 146 нчы карары белән расланган Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Иҗтимагый торак комиссиясе рәисе Комиссия белән гомуми җитәкчелек итә, комиссиянең эш планын һәм юнәлешләрен билгели, раслый, комиссия утырышлары беркетмәләренә имза сала, беркетмәләрдән өземтәләр чыгара, комиссия кабул иткән карарларны раслый, комиссия тарафыннан кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тота.

Иҗтимагый торак комиссиясе секретаре Комиссия эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итә, комиссиянең эш башкаруын алып бара, комиссия әгъзаларын һәм аның утырышына чакырылган затларны көн тәртибе, үткәрү датасы, урыны турында хәбәр итә, фикер алышуга тиешле документлар проектларын һәм башка материалларны җибәрә, Комиссия утырышларын әзерләүне оештыра.

1.2. 4.4. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия карары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора. Комиссия утырышында кабул ителә торган карарлар утырышта рәислек итүче һәм комиссия секретаре кул куйган беркетмәләр белән

0000010764

рәсмиләштерелә. Совет утырышлары беркетмәләренең күчермәләре Совет утырышы уздырылганнан соң 3 эш көне эчендә аның әгъзаларына җибәрелә. Иҗтимагый торак комиссиясе карарлары тәкъдим итү характерына ия.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М. Никифоровка йөкләргә.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов